КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 8 май г.Казань № 387

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру турында» 2018 ел, 29 май, 407 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру турында» 2018 ел, 29 май, 407 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасы турында» 2012 ел, 14 июль, 717 нче карары белән расланган Авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2020 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасының «Авыл территорияләрен тотрыклы үстерү» ярдәмче программасын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

9 нчы пунктның өченче абзацында «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган Авыл җирендә яшәүче гражданнарның (шул исәптән яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең) торак шартларын яхшырту өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдәләр) :

1 нче пунктның беренче абзацында «беренче чиратта» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче пунктның уникенче абзацында «кимендә 70 процентын» сүзләрен «кимендә 50 процентын» сүзләренә алыштырырга;

Кагыйдәләргә теркәлгән 2 нче кушымтада:

3 нче пунктның беренче абзацында «түләүләр акчасын» сүзләреннән соң «яки федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән дәүләт ярдәме күрсәтүнең башка формаларын» сүзләрен өстәргә;

4 нче пунктның «б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) авыл җирендә хезмәт шартнамәсе буенча эшләү яки индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген (төп эш урыны) гамәлгә ашыру (авыл җирендә яшәүче гражданнарның (шул исәптән яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең) торак шартларын яхшырту чараларында катнашучыларның (алга таба – чараларда катнашучылар) – социаль түләүләр алучыларның һәм торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак алучыларның җыелма исемлекләренә (алга таба – җыелма исемлекләр) кертү датасына кимендә бер ел эчендә өзлексез башкару);»;

5 нче пунктта:

«а» пунктчасында «гамәлгә ашыручы» сүзләреннән соң «, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда эшләүче» сүзләрен өстәргә;

«в» пунктчасында «гамәлгә ашыручы» сүзләреннән соң «, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда эшләүче» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле «$б^1$» пунктчасын өстәргә:

«$б^1$) авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда эшләүче гражданнар;»;

9 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле «$9^1$» пунктчасын өстәргә:

«Торак урынның бу Бертип нигезләмәнең 9 нчы пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе-килмәве муниципаль районның башкарма комитеты тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урынны торак урын дип, торак урынны яшәү өчен яраксыз дип һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тану яки бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты итеп реконструкцияләү турындагы нигезләмәне раслау турында» 2006 ел, 28 гыйнвар, 47 нче карары нигезләмәләре нигезендә төзелгән комиссия тарафыннан билгеләнә.»;

10 нчы пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Торак төзү (сатып алу) өчен граждан тарафыннан финанслашу чыганагы буларак торак, шул исәптән кредит оешмасында алынган ипотека кредиты һәм (яки) юридик заттан алынган заем җәлеп ителгән очракта, социаль түләү, гражданны тиешле кредит шартнамәсен (заем шартнамәсен) төзү датасына бу Бертип

нигезләмәнең 4 нче пункты нигезендә социаль түләү алырга хокуклы дип тану һәм аны муниципаль районның башкарма комитеты тарафыннан формалаштырыла торган социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлегенә кертү шартын үтәп, беренче кертемне түләүгә, төп бурычны каплауга һәм кредит (заем) буенча процентлар түләүгә җибәрелергә мөмкин.»;

14 нче пунктның икенче абзацында «Шул ук вакытта төзелеп бетмәгән торак йортның кыйммәте» сүзләрен «Шул ук вакытта төзелеше тәмамланмаган торак йортның кыйммәте» сүзләренә алыштырырга;

17 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Социаль түләү алу хокукына ия булган граждан даими яшәү урыны буенча муниципаль районның башкарма комитетына бу Бертип нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча, түбәндәгеләрне теркәп, гражданнарның, яшь гаиләләр һәм яшь белгечләрнең торак шартларын яхшырту чараларында катнашучылар составына кертү турында гариза (алга таба – гариза) тапшыра:»;

30 нчы пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшь гаиләнең бер генә әгъзасы булса да, авыл җирендә агросәнәгать комплексында, социаль өлкәдә, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда хезмәт шартнамәсе буенча эшләү яки индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген (төп эш урыны) гамәлгә ашыру;»;

«а» пунктчасының өченче абзацында «социаль өлкәдә» сүзләреннән соң «, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«яшь гаиләнең бер генә әгъзасы булса да, авыл җирендә агросәнәгать комплексында, социаль өлкәдә шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда хезмәт шартнамәсе буенча алынган квалификация нигезендә эшләү яки индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген (төп эш урыны) гамәлгә ашыру;»;

«б» пунктчасының өченче абзацында «даими яшәү» сүзләреннән соң «(яшәү урыны буенча теркәлү)», «яки социаль өлкәдә» сүзләреннән соң «, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләрен өстәргә;

31 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«31. Социаль түләү алу хокукына шулай ук авыл җирендә агросәнәгать комплексында, социаль өлкәдә, шулай ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда хезмәт шартнамәсе буенча эшләргә яки индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген (төп эш урыны) гамәлгә ашырырга һәм даими яшәргә теләк белдергән яшь гаиләләр һәм яшь белгечләр ия.»;

32 нче пунктта:

«а» пунктчасының икенче абзацында «яки социаль өлкәдә» сүзләрен «, социаль өлкәдә яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләренә алыштырырга;

«б» пунктчасында «яки социаль өлкәдә» сүзләрен «, социаль өлкәдә яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләренә алыштырырга;

33 нче пунктның «б» пунктчасында «шул исәптән авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлегендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

34 нче пунктның «а», «д» пунктчаларында «агросәнәгать комплексында» сүзләреннән соң «яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләрен өстәргә;

34 нче пунктның «в», «ж» пунктчаларында «агросәнәгать комплексында» сүзләреннән соң «яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләрен өстәргә;

35 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «б$^{1}$» пунктчасы өстәргә:

«б$^{1}$) яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда эшләүче»;

42 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«42. Хезмәт шартнамәсен вакытыннан алда өзгән (индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген туктаткан) очракта, әгәр дә яшь гаилә әгъзасы (яшь белгеч) алты айдан артмаган вакытта авыл җирендә агросәнәгать комплексында, социаль өлкәдә яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда башка эш бирүче белән хезмәт шартнамәсен төзесә яки башка индивидуаль эшмәкәрлек эшчәнлеген (төп эш урынын) оештырса, яшь гаилә әгъзасының (яшь белгечнең) социаль түләүгә хокукы саклана.»;

Кагыйдәләргә теркәлгән 3 нче кушымтада:

12 нче пунктның беренче абзацында «яки социаль өлкәдә» сүзләрен «, социаль өлкәдә яки авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларда» сүзләренә алыштырырга;

13 нче пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урынның яңа милекчесе хезмәт шартнамәсен төзүдән яки җирле үзидарә органнары эшкә урнаштыруда ярдәм күрсәтүдән баш тарткан очракта, яшь белгеч (яшь гаилә әгъзасы (әгъзалары) Татарстан Республикасы чикләрендәге авыл җирендә агросәнәгать комплексына, социаль өлкәгә яки ук авыл хуҗалыгы хайваннары өчен ветеринария эшчәнлеген башкаручы оешмаларга эшкә урнашырга хокуклы.»;

әлеге карар белән расланган Авыл җирендә яшәүче гражданнарның җирле инициативаларына грант ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү кагыйдәләрендә:

исемендә «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

1 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

2 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

6 нчы пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

7 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

8 нче пунктта «башка бюджетара трансферт» сүзләрен «субсидия» сүзенә алыштырырга;

9 нчы пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

10 нчы пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

11 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

13 нче пунктта «башка бюджетара трансфертларны» сүзләрен «субсидияләрне» сүзенә алыштырырга;

14 нче пунктта «башка бюджетара трансфертларның» сүзләрен «субсидияләрнең» сүзенә алыштырырга;

15 нче пунктта «башка бюджетара трансфертларны» сүзләрен «субсидияләрне» сүзенә алыштырырга;

16 нчы пунктта «башка бюджетара трансфертларны» сүзләрен «субсидияләрне» сүзенә алыштырырга;

17 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга;

18 нче пунктта «башка бюджетара трансфертлар» сүзләрен «субсидияләр» сүзенә алыштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин